**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Югары Кәминкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең гражданнары җыены карары**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Югары Кәминкә авыл җирлеге**
**составына керүче Югары Кәминкә авылы,**
**Ибрай Каргалы авылы, Кызыл Яр авылы**
**торак пунктларында гражданнар җыены**
**нәтиҗәләре турында**

09 ноябрь 2019 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 07 ноябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2020 елда Югары Кәминкә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Югары Кәминкә, Ибрай Каргалы, Кызыл Яр торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- су белән тәэмин итүнең урам челтәрен һәм су башняларын ремонтлау (артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, коймаларны ремонтлау һәм буяу, су башняларын буяу, насосны һәм автоматиканы алыштыру);
- җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, трактористка түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга чыгымнарга;
- ротор чапкыч сатып алуга;
- авыл җирлегенең урам-юл челтәрен норматив хәлгә китерүгә (вак таш (щебенка) җәю);
- Кызыл Яр торак пунктында зиратны төзекләндерү, агачларны кисү, коймаларны ремонтлау, буяу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;
- хәбәр итү системасын сатып алу һәм Ибрай Каргалы, Кызыл Яр торак пунктларында урнаштыруга

«ӘЙЕ» « ЮК».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 435 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 248 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 248 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге составына керүче Югары Кәминкә авылында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2020 елда Югары Кәминкә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Югары Кәминкә, Ибрай Каргалы, Кызыл Яр торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- су белән тәэмин итүнең урам челтәрен һәм су башняларын ремонтлау (артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, коймаларны ремонтлау һәм буяу, су башняларын буяу, насосны һәм автоматиканы алыштыру);

- җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракористка түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга чыгымнарга;

- ротор чапкыч сатып алуга;

- авыл җирлегенең урам-юл челтәрен норматив хәлгә китерүгә (вак таш (щебенка) җәю);

- Кызыл Яр торак пунктында зиратны төзекләндерү, агачларны кисү, коймаларны ремонтлау, буяу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;

- хәбәр итү системасын сатып алу һәм Ибрай Каргалы, Кызыл Яр торак пунктларында урнаштыруга - карар кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Югары Кәминкә авылы, Ленин урамы, 19нчы йорт. Чирмешән муниципаль районының рәсми интернет-сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге башлыгы К.М.Гыйләҗев